ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
10.12.2025

КАРАР
№ 1447

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының "2024-2025 елларга Нурлат муниципаль районында демографик хәлне яхшырту" программасын раслау турында» 17.01.2024 №44/1 карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Президентының «2025 елга кадәр чорга Россия Федерациясенең демографик сәясәте концепциясен раслау турында» 09.10.2007 №1351 Указы, Россия Федерациясе Президентының «2024 елга кадәр Россия Федерациясен үстерүнең милли максатлары һәм стратегик бурычлары турында» 07.05.2018 №204 Указы, «Россия Федерациясендә Гаилә елын үткәрү турында» 22.11.2023 №875 Указы нигезендә Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «2024-2025 елларга Нурлат муниципаль районында демографик хәлне яхшырту «программасын раслау турында» 17.01.2024 №44/1 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Исемдә «2024-2025 еллар» сүзләрен «2024-2026 еллар» сүзләренә алмаштырырга.

1.2. 1 пунктта «2024-2025 еллар» сүзләрен «2024-2026 еллар» сүзләренә алмаштырырга.

1.3. Күрсәтелгән карар белән расланган «2024-2025 елларга Нурлат муниципаль районында демографик хәлне яхшырту» муниципаль программасын яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Ә.К. Габдуллин